# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында
гражданнардан үзара салым кертү турында

**18.03.2024 ел** **№ 2**

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьясы, 2004 елның 28 июлендәге 45- ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башлыгының 07.03.2024 елгы 1 номерлы "Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 02.11.2023 елгы 1 номерлы, "2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнардан үзара салым кертү турында" 02.11.2023 елгы 2 номерлы гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында" карары нигезендә Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Беренче Май авылы гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 02.11.2023 елгы № 1, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 02.11.2023 елгы № 2 гражданнар җыены карарларына үзгәрешләр кертергә, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (су белән тәэмин итү челтәрләрен ремонтлау һәм тоту, килешү буенча эш өчен түләү, материаллар, җиһазлар сатып алу, авария хәлләрен бетерү, торбаларны алыштыру);

2) Торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Югары, Урта, Түбән урамнар буенча

юлларны вак ташлау,тракторчыга механикалаштырылган карны этәрү буенча хезмәтләр өчен түләү, торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге юлларны тоту буенча чит оешмаларның хезмәтләре, килешү буенча эш өчен түләү).».

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Урманай авыл җирлеге мәгълүмати стендында, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru),Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Урманай авыл җирлеге Башлыгы Э.Р.Абдуллина